**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

# О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «Об использовании лесов в Республике Татарстан»

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
19 декабря 2018 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 22 мая 2008 года № 22-ЗРТ «Об использовании лесов в Республике Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2008, № 5 (I часть); 2009, № 12 (I часть); 2011, № 6 (I часть); 2012, № 1, № 12 (I часть); 2013, № 12 (I часть); 2014, № 5, № 12 (II часть); 2015, № 11 (I часть); Собрание законодательства Республики Татарстан, 2016, № 40 (часть I); 2017, № 27 (часть I); 2018, № 44 (часть I) следующие изменения:

1) в статье 1:

а) пункт 2 после слов «назначение на должность» дополнить словами «по согласованию с федеральным органом исполнительной власти, осуществляющим функции по контролю и надзору в области лесных отношений,»;

б) пункт 4 изложить в следующей редакции:

«4) организация осуществления Республикой Татарстан отдельных полномочий в области лесных отношений, переданных Российской Федерацией, в соответствии с федеральными законами и предусмотренными частью 10 статьи 83 Лесного кодекса Российской Федерации нормативными правовыми актами;»;

в) пункт 6 изложить в следующей редакции:

«6) обеспечение своевременного представления в федеральный орган исполнительной власти, осуществляющий функции по контролю и надзору в области лесных отношений, отчетности об осуществлении переданных Российской Федерацией отдельных полномочий в области лесных отношений;»;

2) в статье 3:

а) в части 2:

в пункте 7 слова «находящихся в пределах» заменить словами «расположенных в границах»;

в пункте 9 слова «находящихся в пределах» заменить словами «расположенных в границах»;

пункт 10 признать утратившим силу;

б) в части 3:

пункт 4 дополнить словами «, либо лицами, осуществляющими использование лесов на основании сервитута или установленного в целях, предусмотренных статьей $39^{37}$ Земельного кодекса Российской Федерации, публичного сервитута»;

пункт 8 признать утратившим силу;

пункт 9 изложить в следующей редакции:

«9) предоставление лесных участков, расположенных в границах земель лесного фонда, в постоянное (бессрочное) пользование, аренду, безвозмездное пользование, за исключением случаев, предусмотренных пунктами 7 и 9 части 2 настоящей статьи; заключение договоров купли-продажи лесных насаждений, расположенных на землях лесного фонда; подготовка, организация и проведение торгов на право заключения договоров аренды лесных участков, находящихся в государственной или муниципальной собственности, аукциона на право заключения договоров купли-продажи лесных насаждений; установление сервитутов в отношении лесных участков, расположенных в границах земель лесного фонда;»;

пункт 10 изложить в следующей редакции:

«10) выдача разрешений на выполнение работ по геологическому изучению недр на землях лесного фонда;»;

в пункте $13^{3}$ слова «занятым лесными насаждениями» заменить словами «на которых расположены леса»;

пункт $13^{5}$ изложить в следующей редакции:

«$13^{5}$) проектирование лесных участков на землях лесного фонда;»;

дополнить пунктом $13^{9}$ следующего содержания:

«$13^{9}$) осуществление на землях лесного фонда охраны лесов (в том числе осуществление мер пожарной безопасности и тушение лесных пожаров, за исключением выполнения взрывных работ в целях локализации и ликвидации лесных пожаров и осуществления мероприятий по искусственному вызыванию осадков в целях тушения лесных пожаров), защиты лесов (за исключением лесозащитного районирования и государственного лесопатологического мониторинга), воспроизводства лесов (за исключением лесосеменного районирования, формирования федерального фонда семян лесных растений и государственного мониторинга воспроизводства лесов), лесоразведения;»;

3) в статье 10:

а) в абзаце третьем части 1 слова «и валежных» исключить;

б) дополнить частью 6 следующего содержания:

«6. Заготовка валежника осуществляется в течение всего года путем сбора лежащих на поверхности земли стволов деревьев или их частей, не являющихся порубочными остатками в местах проведения лесосечных работ, и образовавшихся вследствие естественного отмирания деревьев, при их повреждении вредными организмами, буреломе, снеговале. Заготовка валежника осуществляется без

проведения рубок лесных насаждений исключительно ручным способом с применением инструментов, приспособлений и механизмов, приводимых в использование ручной силой.».

**Статья 2**

Признать утратившими силу:

1) подпункт «а» пункта 1 статьи 1 Закона Республики Татарстан от 14 мая 2014 года № 39-ЗРТ «О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «Об использовании лесов в Республике Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2014, № 5);

2) подпункт «а» пункта 1 статьи 1 Закона Республики Татарстан от 19 ноября 2016 года № 89-ЗРТ «О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «Об использовании лесов в Республике Татарстан» (Собрание законодательства Республики Татарстан, 2016, № 40 (часть I).

**Статья 3**

1. Настоящий Закон вступает в силу с 1 января 2019 года, за исключением положений, для которых настоящей статьей установлен иной срок вступления их в силу.

2. Абзацы второй и третий подпункта «а», абзацы второй, шестой и седьмой подпункта «б» пункта 2 статьи 1 настоящего Закона вступают в силу со дня официального опубликования настоящего Закона.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
22 декабря 2018 года
№ 109-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 19 декабрендә
кабул ителде

## 1 статья

«Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» 2008 елның 22 маендагы 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш); 2012, № 1, № 12 (I өлеш); 2013, № 12 (I өлеш); 2014, № 5, № 12 (II өлеш); 2015, № 11 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 44 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяда:

а) 2 пунктта «гамәлгә ашыручы җитәкчесен» сүзләреннән соң «урман мөнәсәбәтләре өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек функцияләрен гамәлгә ашыручы вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы белән килештереп» сүзләрен өстәргә;

б) 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) урман мөнәсәбәтләре өлкәсендә Россия Федерациясе тарафыннан тапшырылган аерым вәкаләтләрне федераль законнар һәм Россия Федерациясе Урман кодексының 83 статьясындагы 10 өлешендә каралган норматив хокукый актлар нигезендә Татарстан Республикасы тарафыннан гамәлгә ашыру эшчәнлеген оештыру;»;

в) 6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) урман мөнәсәбәтләре өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органына урман мөнәсәбәтләре өлкәсендә Россия Федерациясе тарафыннан тапшырылган аерым вәкаләтләрне гамәлгә ашыру турында хисапны үз вакытында бирүне тәэмин итү;»;

2) 3 статьяда:

а) 2 өлештә:

7 пунктта «чикләрендәге» сүзләрен «чикләрендә урнашкан» сүзләренә алмаштырырга;

9 пунктта «чикләрендәге» сүзләрен «чикләрендә урнашкан» сүзләренә алмаштырырга;

10 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

б) 3 өлештә:

4 пунктка «затлар тарафыннан» сүзләреннән соң «йә урманнардан файдалануны сервитут нигезендә яисә Россия Федерациясе Җир кодексының $39^{37}$ статьясында каралган максатларда билгеләнгән гавами сервитут нигезендә гамәлгә ашыручы затлар тарафыннан» сүзләрен өстәргә;

8 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) әлеге статьяның 2 өлешендәге 7 һәм 9 пунктларында каралган очраклардан тыш, урман фонды җирләре чикләрендә урнашкан урман кишәрлекләрен даими (чикләнмәгән вакытка) файдалануга, арендага, түләүсез файдалануга бирү; урман фонды җирләрендә урнашкан урман утыртмаларын сату-алу килешүләрен төзү; дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге урман кишәрлекләрен арендалау шартнамәләрен төзү хокукына торглар, урман утыртмаларын сату-алу шартнамәләрен төзү хокукына аукционнар әзерләү, оештыру һәм уздыру; урман фонды җирләре чикләрендә урнашкан урман кишәрлекләренә карата сервитутлар билгеләү;»;

10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10) урман фонды җирләрендә җир асты байлыкларын геологик өйрәнү эшләрен башкаруга рөхсәтләр бирү;»;

$13^{3}$ пунктта «урман утыртмалары биләгән» сүзләрен «урманнар урнашкан» сүзләренә алмаштырырга;

$13^{5}$ пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$13^{5}$) урман фонды җирләрендә урман кишәрлекләрен проектлау;»;

түбәндәге эчтәлекле $13^{9}$ пункт өстәргә:

«$13^{9}$) урман фонды җирләрендә урманнарны саклауны (шул исәптән янгын куркынычсызлыгы чараларын гамәлгә ашыру һәм урман янгыннарын сүндерү, моңа урман янгыннарын локальләштерү һәм туктату максатларында шартлату эшләрен башкару һәм урман янгыннарын сүндерү максатларында ясалма рәвештә яңгыр яудыру чараларын гамәлгә ашыру керми), урманнарны яклауны (моңа урманнарны яклауны районлаштыру һәм урман авыруларын дәүләт тарафыннан мониторинглау керми), урманнарны торгызуны (моңа урман орлыклары буенча районлаштыру, урман үсемлекләре орлыкларының федераль фондын булдыру һәм урманнарны торгызуны дәүләт тарафыннан мониторинглау керми), урман үрчетүне гамәлгә ашыру;»;

3) 10 статьяда:

а) 1 өлешнең өченче абзацында «һәм ауган» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 6 өлеш өстәргә:

«6. Агач коры-сарысын әзерләү ел дәвамында гамәлгә ашырыла, ул урман кисү эшләрен башкару урыннарында кискәннән калган өлешләр булып тормаган һәм агачларның табигый коруы, корткыч организмнар белән зарарлануы, давыл аудару, кар басу аркасында барлыкка килгән җир өстендә ятучы агач кәүсәләрен яисә аларның өлешләрен җыеп башкарыла. Агач коры-сарысын әзерләү урман утыртмаларын кул көче белән кулланыла торган эш кораллары, җайланмалар һәм механизмнар белән бары тик кулдан кисү юлы белән генә башкарыла.».

**2 статья**

Үз көчен югалткан дип танырга:

1) «Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 14 маендагы 39-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 1 пунктының «а» пунктчасын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2014, № 5);

2) «Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2016 елның 19 ноябрендәге 89-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 1 пунктының «а» пунктчасын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2016, № 40 (I өлеш).

**3 статья**

1. Әлеге Закон, бу статья белән үз көчләренә керүнең башка сроклары билгеләнгән нигезләмәләреннән тыш, 2019 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 2 пунктының «а» пунктчасындагы икенче һәм өченче абзацлар, «б» пунктчасындагы икенче, алтынчы һәм җиденче абзацлар әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2018 ел, 22 декабрь
№ 109-ТРЗ